РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«10» апрель 2023 ел г. Альметьевск № 869

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Башкарма комитетының
«Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында»
2021 елның 27 маендагы 748 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында 2022 елның 14 июленнән № 312-ФЗ,«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 237-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 748 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада

- 2 бүлекнең 2.6.1 пунктындагы 8) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмәләр - Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды;»;

- 2 бүлекнең 2.8.3.2 пунктындагы 13 пунктчада «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов